**СОВЕТ**
**НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы,
Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail:Nkin.Ars@tatar.ru

**Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**“22”август 2022 ел** **№ 78**

**Җир салымы турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл җирлеге Уставына таянып, Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы **карар бирде:**

1. 2022 елның 1 гыйнварыннан Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә әлеге территориядә җир салымын мәҗбүри түләүгә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Җир салымының салым ставкасын кадастр бәясеннән түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

2.1. Гомуми файдаланудагы 1-3 категорияле автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләүгә өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата 0,05 процент;

2.2. Торак пунктларда авыл хуҗалыгы файдалануы зоналары составындагы авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә кертелгән җир кишәрлекләренә карата һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган җирләргә карата 0,3 процент;

2.3. Оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнеше чикләнгән җир кишәрлекләренә карата 0,3 процент;

2.4. Торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган җир кишәрлекләренә карата (эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) 0,08 процент;

2.5. «Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү

хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,08 процент;

2.6. Җитештерү һәм административ биналар, корылмалар, сәнәгать корылмалары, коммуналь хуҗалык, матди-техник, азык-төлек белән тәэмин итү, торак пунктлар җирләре составында сату һәм әзерләү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата 1,2 процент;

2.7. Башка җир участокларына карата 1,5 процент.

3. Салым ташламаларын түбәндәгечә бирергә:

3.1. 100% күләмендә җир салымын түләүдән азат итү рәвешендә:

3.1.1. муниципаль учреждениеләргә-әлеге карарның 2 пунктының 2.1 пунктчасында күрсәтелгән яр буе, парклар, аллеялар, скверлардан тыш, мәйданнар, урамнар, машина юллары, автомобиль юллары биләгән гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата;

3.1.2. оешмаларга һәм учреждениеләргә-зиратлар, үләт базлары, граждан күмүләре, каты көнкүреш калдыклары полигоннары биләп торган җир кишәрлекләренә карата;

3.1.3. Әфганстан Республикасында һәм сугыш хәрәкәтләре алып барылган башка илләрдә интернациональ бурычын үтәгән гражданнарга;

3.2. җир салымын түләүдән өлешчә азат итү рәвешендә:

3.2.1. Яңа Кенәр авыл җирлеге территориясендә урнашкан, федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан, җирле бюджеттан финанслана торган дәүләт хакимияте һәм идарә органнарына, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә җирнең кадастр бәясенең 0,52 проценты күләмендә салымның киметелгән ставкасын куллану рәвешендә;

3.3. Шәхси ярдәмче хуҗалык өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата салым түләүче сайлавы буенча бер җир кишәрлеге өчен салым түләүдән тулысынча азат итү рәвешендә:

3.3.1. Ирекле янгын сүндерүчеләргә һәм янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләренә, салым чоры дәвамында ирекле янгын сүндерү командалары (дружиналары) составында янгын сүндерүдә турыдан-туры катнашу шарты белән.

4. Түбәндәгене билгеләргә:

Салым чоры дип календарь ел таныла.

Салым түләүче оешмалар өчен хисап чорлары дип беренче квартал, икенче квартал һәм календарь елның өченче кварталы таныла.

Салым салым түләүче оешмалар тарафыннан үткән салым чорыннан соң килә торган елның 1 мартыннан да соңга калмыйча түләнергә тиеш. Салым буенча аванс түләүләре салым түләүче оешмалар тарафыннан узган хисап чорыннан соң килә торган айның соңгы көненнән дә соңга калмыйча түләнергә тиеш.

5. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

6. 2022 елның 1 гыйнварыннан Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- «Җир салымы турында» 2017 елның 27 октябрендәге 66 номерлы;

- "Җир салымы турында» 2017 елның 27 октябрендә 66 номерлы Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында » 2019 елның 21 августындагы 121 номерлы карарын;

- «Җир салымы турында» 2017 елның 27 октябрендәге 66 номерлы Апаз авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 18 ноябрендәге 133 номерлы;

- «Җир салымы турында» 2017 елның 27 октябрендәге 66 номерлы Апаз авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 06 июнендәге 73 номерлы.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Ә.Ә. Гайфуллин